КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 11 декабрь г.Казань № 1113

«2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру чаралары хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетын 2019 елның 1 гыйнварыннан үтәү өчен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең баш администраторларына:

Татарстан Республикасы бюджетына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр керүне тәэмин итү, шулай ук аларны түләү буенча бурычларны киметү чараларын күрергә;

квартал саен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән вакытларда һәм форма нигезендә ай саен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына керемнәр керү фаразларын кертергә;

квартал саен керемнәр буенча бюджетның факттагы үтәлеше фаразда каралганнан тайпылу сәбәпләрен күрсәтеп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән вакытларда керемнәр өлешендә Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында квартал саен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына аналитик материаллар кертергә;

үз ведомстволары буйсынуындагы бюджет керемнәре администраторлары исемлекләрен билгеләү турында норматив хокукый актлар кабул итүне тәэмин итәргә;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары керемнәрен бюджет классификациясенең тиешле кодларына күчерү максатларында ачыкланмаган керемнәрне оператив рәвештә ачыклауны гамәлгә ашырырга;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслаган тәртиптә һәм срокларда Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре чыганаклары реестрын формалаштыру һәм алып бару өчен кирәкле мәгълүматны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына тапшыруны тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары вәкаләтләре һәм (яисә) алар идарә итә торган Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре составы үзгәргән очракта, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына закон чыгару һәм башка норматив хокукый актлар кергән көннән өч эш көне эчендә үзгәрешләр турында мәгълүмат бирергә, нигезендә администрацияләнүче керемнәр вәкаләтләре һәм (яисә) составы үзгәртелә.

3. Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторларына квартал саен Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы билгеләгән вакытларда һәм форма нигезендә, элек бирелгән бюджет кредитларын каплауга күздә тотылган акчаны кире кайтару суммаларын исәпкә алып, чираттагы кварталга Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын эчке һәм тышкы финанслау чыганаклары акчасын каплау һәм ай саен җәлеп итү фаразларын кертергә.

4. Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына җирле бюджетларны үтәү турындагы мәгълүматны, бу карарның 2 пунктындагы өченче, дүртенче абзацларда һәм 3 пунктында күздә тотылган шундый ук мәгълүматны Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына кертүне тәкъдим итәргә.

5. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

2019 елның 1 гыйнварына торышына файдаланылмаган Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджетына һәм җирле бюджетларга бирелгән максатчан билгеләнешле субвенцияләр, субсидияләр, бүтән бюджетара трансфертларның калган өлеше, финанслау чыганагы булып Россия Федерациясе Президентының резерв фондының бюджет ассигнованиеләре торган бюджетара трансфертлардан тыш, 2019 елның беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш;

кире кайтарылган бюджетара трансфертлардан Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре белән идарә итүче Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең баш администраторлары тарафыннан субвенцияләр, субсидияләр, максатчан билгеләнешкә ия булган башка бюджетара трансфертлар рәвешендә алынган һәм 2018 елда файдаланылмый калган бюджетара трансфертларга ихтыяҗ барлыгы (юклыгы) турында карар кабул итү, шулай ук 2019 елда аларны шул ук максатларга юнәлтү ихтыяҗы барлыгы турында карар кабул ителгән әлеге бюджетара трансфертларны Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды бюджетына һәм җирле бюджетларга кире кайтару бюджеты акчасының баш администраторы билгеләгән тәртиптә формалашкан тиешле бюджет чыгымнары турында хисапны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча әлеге акча Татарстан Республикасы бюджетына кергән көннән соң 30 эш көненнән дә соңга калмый гамәлгә ашырыла;

әлеге пунктның өченче абзацында күрсәтелгән вакытны саклау максатларында

кире кайтарылган бюджетара трансфертлардан Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре белән идарә итүче Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең баш администраторлары әлеге пунктның өченче абзацында каралган, Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фондының идарә органы, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары тапшырган хисапларны карап тикшерүне һәм субвенцияләр, субсидияләр, максатчан билгеләнешкә ия булган башка бюджетара трансфертлар рәвешендә алынган һәм 2018 елда файдаланылмый калган бюджетара трансфертларны 2019 елда шул ук максатларга юнәлтү ихтыяҗы барлыгы турында карарны әлеге акча Татарстан Республикасы бюджетына кергән көннән соң 10 эш көне эчендә, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы раслаган форма буенча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештерүгә җибәрүне тәэмин итә;

2018 елда бирелгән һәм максатчан билгеләнешкә ия бюджетара трансфертларның калган акчасына ихтыяҗ булуы турында карарлар күрсәтелгән калдык акчадан артмаган күләмдә кабул ителә:

Татарстан Республикасының Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды кабул иткән, бюджетара трансфертларның калган акча аларны финанслау чыганагы булып торган үтәлмәгән бюджет йөкләмәләре булганда,

әгәр 2019 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетка файдаланылмый калган бюджетара трансфертларны биргәндә элегрәк билгеләнгән максатларга туры килә торган максатларга бюджетара трансфертлар бирү каралмаган һәм бюджетара трансфертларның калган акчасы аларны финанслау чыганагы булып торган муниципаль район, округы бюджеты акчасын алучы үз өстенә алган үтәлмәгән бюджет йөкләмәләре булган булса;

2019 елның 1 февраленә кадәр дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләр субсидиянең калган акчасын Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтаруны тәэмин итә:

аларга 2018 елда дәүләт биреме белән билгеләнгән ирешелмәгән күрсәткечләргә туры килә торган күләмдә дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт биремен башкаруны финанслар белән тәэмин итүгә бирелгән. Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүчеләр дәүләт биремнәрен үтәү турында хисаплар нигезендә күрсәтелгән акчаны кире кайтаруны тикшерүдә тота;

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.1 статьясындагы 1 пунктның икенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелгән, аларга карата 2019 елда шул ук максатларга юнәлдерелгән ихтыяҗ булу Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә расланмаган;

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүчеләр федераль башкарма хакимият органына тапшыра торган бюджетара трансфертлардан файдалану турында хисаплар Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештерелергә тиеш;

социаль-мәдәни өлкә һәм торак-коммуналь хуҗалык объектларын дәүләт милкеннән муниципаль милеккә тапшыру, агымдагы елда тапшырылган

объектларның эшчәнлеген тәэмин итү чыгымнарын каплау чыганагын билгеләп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокук актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

6. Карарга теркәлгән Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга бирелә торган максатчан билгеләнештәге, аларны күчерү буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүчеләр кабул иткән карар нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасын алучы вәкаләтләрен 2019 елда Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенә тапшырган бюджетара трансфертлар исемлеген расларга.

7. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына:

2019 елның 1 февраленә кадәр 2019 елда чыгымнар буенча Татарстан Республикасы бюджеты үтәлешен тәэмин итүгә юнәлгән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты норматив хокукый актлары проектларын билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә;

бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы дәүләт программаларын «2019 елга Татарстан Республикасы бюджеты һәм 2020 һәм 2020 елларга план чоры турында» 2017 елның 30 ноябрендәге 85-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына туры китерүне тәэмин итәргә.

8. Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм дәүләт казна учреждениеләре булган дәүләт заказчыларына товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә Татарстан Республикасы исеменнән төзелгән, дәүләт контрактларына түләүгә әлеге дәүләт контрактлары шартлары нигезендә 2018 елда түләнергә тиешле бюджет ассигнованиеләренең калган өлешләре турында 2019 елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына мәгълүмат кертергә.

9. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

202 елның 1 гыйварына кадәр:

эш хакы буенча бюджет йөкләмәләренең билгеләнгән тәртиптә расланган лимитларын агымдагы финанс елында башка максатларга күздә тотылган бюджет йөкләмәләре лимитларын файдалану буенча экономия хисабына арттыру, моңа Россия Федерациясе законнары нигезендә хезмәт өчен түләү буенча түләүләргә исәпләнә торган акчаны түләүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары керми;

хезмәт өчен түләү буенча түләүләргә исәпләнә торган акчаны түләүгә билгеләнгән тәртиптә расланган бюджет йөкләмәләре лимитларын башка максатларга күздә тотылган бюджет йөкләмәләре лимитларын арттыру максатларында киметү, моңа эш хакы буенча бюджет йөкләмәләре лимитлары керми;

Татарстан Республикасы дәүләт милкәтен хосусыйлаштыру буенча конкурста, аукционда катнашуга гаризаларны тәэмин итү сыйфатында торгларда катнашучылар кертә торган акча, Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен сатып алуларда катнашучылар Татарстан Республикасы исеменнән төзелгән дәүләт контрактлары үтәлешен тәэмин итү сыйфатында кертә торган акча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментында учреждениеләрнең вакытлыча карамагына керә торган акча белән башкарыла торган операцияләрнең исәбен алу өчен ачкан Татарстан Республикасы учреждениеләренең

шәхси исәпләрендә исәпкә алына;

Татарстан Республикасы бюджеты акчасын алучылар Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән түләнергә тиешле товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга һәм хезмәтләр күрсәтүгә шартнамәләр (дәүләт контрактлары) төзегәндә түбәндәге аванс түләүләрен күздә тотарга хокуклы дип билгеләргә:

шартнамә (контракт) суммасының 100 процентына кадәр күләмдә – ягулык-майлау материаллары, транспорт чаралары, юлламалар, авиа- һәм тимер юл билетлары, шәһәр һәм шәһәр яны транспорты белән бару өчен билетлар, ашыгыч әһәмияткә ия булган медикаментлар (кеше тормышы өчен куркыныч янаган хәлләрдә кичектергесез медицина ярдәме күрсәтү өчен таләп ителә торган медикаментлар) сатып алу шартнамәләре (контрактлары), Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы чит ил оешмалары белән төзи торган Россия Федерациясе гражданнарына Россия Федерациясе территориясеннән читтә дәвалау үткәрү турындагы шартнамәләр, белем алу (эштән азат ителү куркынычы янаган хезмәткәрләргә, инвестиция проектлары нигезендә җитештерүне реструктурлаштыру һәм модернизацияләүне гамәлгә ашыручы җитештерү өлкәсе оешмалары хезмәткәрләренә белем бирү (квалификация күтәрү, һөнәри әзерләү, яңадан әзерләү, алдан әзерләү, зарарлы җитештерүдән чыгару максатларында, хезмәт шартлары зарарлы һәм авыр булган хатын-кызларга алдан һөнәр белеме бирү) хакындагы, басма матбугатка язылу турындагы, элемтә, кабельле һәм спутник телевидениесе хезмәтләре күрсәтү турындагы шартнамәләр, биналарны арендалау, мөлкәтне иминләштерү турындагы шартнамәләр, проектлау документларына дәүләт экспертизасы үткәрү, мәгълүмат белән тәэмин итү, транспортта йөртү хезмәтләре күрсәтүгә түләү хакындагы шартнамәләр, фәнни, мәдәни, экскурсия һәм спорт чаралары үткәрү турындагы шартнамәләр буенча;

шартнамә (контракт) суммасының 30 процентына кадәр күләмдә – Россия Федерациясе законнары белән башкасы күздә тотылмаса, калган шартнамәләр (контрактлар) буенча;

товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләреннән тыш (алга таба – юридик затлар), шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү 2019 елда Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезләмәләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

10. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына:

бюджет акчасы белән баш эш итүчеләргә бюджет ассигнованиеләре турында хәбәрнамәләр һәм 2019 елга һәм 2020 һәм 2021 елларның план чорына Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет язуында билгеләнгән күләмдә бюджет йөкләмәләре лимитын җиткерергә;

2019 елның 15 февраленә кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына товарлар сатып алуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә Татарстан Республикасы исеменнән төзелгән дәүләт контрактлары өчен түләүгә файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләре суммасы кысаларында әлеге дәүләт контрактлары шартлары нигезендә 2018 елда түләнергә тиешле, 2019 елда әлеге максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга юнәлдерелә торган бюджет ассигнованиеләре күләмнәре турында тәкъдимнәр кертергә;

муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар сатып алуга, эшләр башкаруга һәм хезмәтләр күрсәтүгә бәйле рәвештә сарыф ителә торган субсидияләрне муниципаль берәмлекләргә күчерүне Россия Федерациясенең сатып алулар өлкәсендәге контракт системасы турындагы законнары нигезендә төзелгән контракт (шартнамә) булганда түбәндәге тәртиптә гамәлгә ашырырга:

контрактта (шартнамәдә) билгеләнгән күләмдә – аванс түләү өчен;

эшләр башкаруны, хезмәтләр күрсәтүне, товар кайтартуны раслый торган документлар булганда – контракт (шартнамә) буенча башкарылган эшләргә, күрсәтелгән хезмәтләргә, кайтартылган товарга түләү өчен.

11. Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүчеләргә:

үзләренә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм җыелма бюджет исемлегенең расланган күрсәткечләре нигезендә бюджет йөкләмәләре лимитларын ведомство буйсынуындагы эш итүчеләр һәм (яки) Татарстан Республикасы бюджеты акчасын алучылар арасында бүләргә;

максатчан билгеләнешкә ия булган бюджетара трансфертлар биргәндә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә бюджетлар арасындагы исәп-хисаплар буенча хәбәрнамәләр җиткерергә.

12. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

бу карарга теркәлгән 1 нче кушымта нигезендә 2019 елга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым актлары гамәлен озайтырга;

бу карарга теркәлгән 2 нче кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актларының финанслау чыганаклары белән тәэмин ителмәгән аерым нормалары гамәлен 2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр туктатып торырга.

13. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 11 декабрь, 1113 нче
карары белән расланды

**Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга бирелә торган максатчан билгеләнештәге, аларны күчерү буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүчеләр кабул иткән карар нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасын алучы вәкаләтләрен 2019 елда Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенә тапшырган бюджетара трансфертлар**
**Исемлеге**

| Бюджетара трансферт исеме | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче исеме |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу өчен бюджетларына субвенцияләр | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Граждан хәле актларын язу идарәсе |
| Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыруга бюджетларга субвенцияләр | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы |
| Россия Федерациясендә гомум юрисдикциядәге федераль судларның хөкемче утырышчыларына кандидатлар исемлекләрен төзү (үзгәрешләр кертү) буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга бюджетларга субвенцияләр | Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы |
| Мәдәният өлкәсенә ярдәм күрсәтү өчен бюджетларга субсидияләр | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы |
| Халык саны 300 меңгә кадәр булган торак пунктларда муниципаль театрларның матди-техник базасын ныгыту һәм иҗади эшчәнлеккә ярдәм итү өчен бюджетларга субсидияләр | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы |
| Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү чараларын тормышка ашыру өчен бюджетларга субсидияләр | Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча министрлык |

| 1 | 2 |
|---|---|
| Авыл территорияләрен тотрыклы үстерү чараларын гамәлгә ашыруга бюджетларга субсидияләр | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы |
| Муниципаль милек объектларына капитал салуларны финанслашуга бюджетларга субсидияләр | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы |

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 11 декабрь, 1113 нче
карарына 1 нче кушымта

**Гамәлләре 2019 елга озайтыла торган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актлары исемлеге**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары:

«2005 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан социаль ярдәмнең аерым чараларын тормышка ашыруга бүлеп бирелә торган акчаны тоту тәртибен раслау турында» 2005 ел, 21 март, 140 нчы;

«2006 елда гражданнарның аерым категорияләренә торакка һәм коммуналь хезмәтләргә түләү өчен субсидияләр бирүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелә торган акчаны тоту тәртибен раслау турында» 2006 ел, 16 февраль, 55 нче;

«2008 елда Татарстан Республикасы дәүләт милкенә караган һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә урнашкан архив документларын саклау, комплектлау, исәпкә алу һәм файдалану буенча җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субвенция бирү тәртибен раслау турында» 2008 ел, 21 май, 329 нчы;

«2008 елда хәрби хезмәткә чакыру буенча хезмәт итүче хәрби хезмәткәрнең йөкле хатынына бер тапкыр бирелә торган пособие һәм хәрби хезмәткә чакыру буенча хезмәт итүче хәрби хезмәткәр баласына айлык пособие түләүгә федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субвенцияләр рәвешендә бирелә торган акчаны сарыф итү кагыйдәләрен раслау турында» 2008 ел, 7 июль, 478 нче;

«Дарулар белән тәэмин итү өлкәсендәге аерым вәкаләтләрне башкарганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү максатларында 2010 елда федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлардан файдалану тәртибен раслау турында» 2008 ел, 26 декабрь, 923 нче;

«2010 елда Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләренә Татарстан Республикасы бюджетында җәмәгать транспорты хезмәтләре күрсәтүдән бертигез файдалануны тәэмин итү өчен каралган субсидияләрне һәм субвенцияләрне бирү турында» 2009 ел, 10 март, 134 нче;

«Кирәкле дару чаралары, медицина әһәмиятендәге әйберләр, шулай ук инвалид балалар өчен дәвалану туклануының махсуслаштырылган продуктлары белән тәэмин итү өлешендә түләүсез өстәмә медицина ярдәме күрсәтү буенча гражданнарның аерым категорияләренә социаль хезмәт күрсәтүне финанслар белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2009 ел, 20 апрель, 246 нчы;

«2011 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан «Татарстан Республикасы

студентлар лигасы» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасына субсидияләр бирү турында» 2011 ел, 23 май, 406 нчы;

«Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга булышлык күрсәтү фонды турында» 2007 ел, 21 июль, ФЗ-185 нче Федераль закон кысаларында гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү өчен субсидияләр бирү кагыйдәләрен раслау турында» 2011 ел, 27 май, 427 нче;

«2017 елга Татарстан Республикасы медицина оешмаларында Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминиятенең нигез программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүне финаслар белән тәэмин итү турында» 2016 ел, 31 декабрь, 1089 нчы;

«Авиация кулланып медицина ярдәме (ашыгыч махсуслашкан медицина ярдәме) күрсәтү өчен авиация техникасына сатып алуны финаслар белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 14 июнь, 388 нче.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 11 декабрь, 1113 нче
карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актларының гамәлләре 2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр туктатылып торыла торган, финанслау чыганаклары белән тәэмин ителмәгән аерым нормалары исемлеге**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Радиоактив матдәләр һәм радиоактив калдыкларның исәбен алу һәм тикшерүдә тоту буенча региональ мәгълүмат-анализ үзәген төзү турында» 2002 ел, 19 сентябрь, 556 нчы карарының 4 нче пункты.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль берәмлекләрне социаль-икътисадый үстерүне һәм аларның җәмәгать финанслары белән сыйфатлы идарә итүне стимуллаштыру фондыннан Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләренә дотацияләр бирү тәртибе турында» 2007 ел, 16 июль, 303 нче карары.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Химиклар көнен бәйрәм итү турында, 2011 ел, 15 июнь, 481 нче карарының 3 нче пункты.

4. Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслау өлешендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Икътисадый әһәмияткә ия булган төбәк программаларын раслау турында» 2011 ел, 25 июль, 580 нче карары.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Күмү урыннарын карап тоту чыгымнарын финанслашу өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына субсидияләр бирү кагыйдәләрен раслау турында» 2011 ел, 18 ноябрь, 946 нчы карарының 3 нче пункты.

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында ирекле янгын сүндерүчеләргә, янгыннан ирекле саклау хезмәткәрләренә һәм аларның гаиләләре әгъзаларына социаль ярдәм күрсәтү һәм аларны яклау чаралары турында» 2012 ел, 10 август, 694 нче карары.

7. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 – 2020 елларга Татарстан Республикасында Товарлы аквакультураны (товарлы балыкчылыкны) үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2015 ел, 28 декабрь, 991 нче карары.

_______________________________